Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының кырык җиденче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

15 октябрь, 2024 ел — № 352

«Муниципаль берәмлекләр башлыклары, муниципаль район башлыгы урынбасары, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының контроль-хисап палатасы рәисе һәм муниципаль хезмәткәрләре хезмәтенә түләү турында» 2021 елның 1 апрелендәге 63 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Даими нигездә вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының хезмәт өчен түләүгә чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре башлыкларына, муниципаль район башлыгы урынбасарына, контроль-хисап палатасы Рәисенә һәм муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү турында» 2021 елның 1 апрелендәге 63 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының 2022 елның 30 мартындагы 152 номерлы, 2022 елның 8 сентябрендәге 187 номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 190 номерлы, 2022 елның 29 декабрендәге 210 номерлы, 2023 елның 18 маендагы 244 номерлы, 2024 елның 22 маеннан 320 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) кертергә.) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. 1.2 подпунктта «13233» саннарын «13990»саннарына алмаштырырга.

1.2. «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары» таблицасына 1 нче кушымтада яңа редакциядә бәян итәргә (әлеге карарга кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

Питрәч муниципаль районы Советы
карарына кушымта
15 октябрь, 2024 ел № 352

## Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль район башлыгы урынбасарының, контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт өчен түләү күләмнәре һәм шартлары

| Вазыйфа исеме | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем | 9 төркем | 10 төркем | 11 төркем | 12 төркем |
| Муниципаль район башлыгы | 37 036 | | | | |
| Муниципаль район башлыгы урынбасары | 33 333 | | | | |
| Контроль-хисап палатасы рәисе | 33 333 | | | | |
| Авыл җирлеге башлыгы | - | 26 029 | 22 810 | 20 991 | 19 173 |